**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан

13.02.2016 № 01-02/50

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү тәртибен раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясендә аерым дәүләт хезмәтләре вазыйфаларында, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында булучылар, башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү тәртибе турында, һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 650 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү Тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгына (Латыева Т.Ю.) тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы аппаратындагы һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларындагы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук алар белән хезмәт килешүләре төзегәндә гражданнарны әлеге боерык белән таныштыруны;

Тәртипне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының “Коррупциягә каршы сәясәт” мәгълүмати стендына урнаштыруны.

3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында мәгълүмат стендларына мәгълүмат урнаштыруга җаваплы затларга Тәртипне суд участоклары стендларына урнаштырырга.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (Сафин А.Г.) әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең “Коррупциягә каршы тору” бүлегендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.И.Заһидуллин

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
2016 елның 13
февралендәге 01-02/50
номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең аларга мөнәсәбәттә эш бирүче вәкиле булып Татарстан Республикасы юстиция министры (алга таба – министр) торган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү тәртибен регламентлый.

2. Белдерү гражданлык хезмәткәре тарафыннан язма формада, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү (алга таба – белдерү) рәвешендә әлеге Тәртипкә Кушымтада күрсәтелгән формада языла һәм министрга юллана.

3. Министр белдерү кәгазен алдан карап чыгу өчен өч эш көне дәвамында коррупция яки башка төр хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) юллый.

4. Белдерү кәгазен алдан карау барышында җаваплы зат белдерү кәгазен юллаган гражданлык хезмәткәреннән анда язылган хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга тиешле тәртиптә таләпләр юллауны оештырырга хокуклы.

5. Белдерү кәгазен алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат мотивлаштырылган нәтиҗә әзерли. Белдерү кәгазе, нәтиҗә һәм алдан карау барышында алынган башка материаллар җаваплы зат тарафыннан белдерү кәгазе алынганнан соңгы җиде эш көне дәвамында аның тарафыннан Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тәкъдим ителә.

6. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган таләпләр юлланган очракта, белдерү кәгазе, нәтиҗә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан белдерү кәгазе алынганнан соңгы 45 көн дәвамында Комиссия рәисенә тәкъдим ителә. Билгеләнгән вакыт дәвамлылыгы Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә арттырыла алмый.

7. Белдерү кәгазе, нәтиҗә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2016 елның 13 февралендәге Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссиясе турындагы 01-02/49 номерлы Нигезләмәсе нигезендә карала.

Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгындагы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү тәртибенә кушымта

Татарстан
Республикасы юстиция
министры
Л.Ю.Глуховага

______________________________
(вазыйфасының аталышы)
______________________________
______________________________
(Ф.И.Ә.и., адрес, телефон номеры)

## Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык туу турында белдерү кәгазе

Миндә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган (кирәклесенең астына сызарга) шәхси кызыксынучанлык туу турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынучанлык тууга нигез булып торучы хәлләр: ________________________________________________
______________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларны гамәлгә ашыруга йогынты ясый торган яки йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: __________________________________________
______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки көйләү буенча тәкъдим ителә торган чаралар:__________________________________________________________
______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту тәртипләрен саклау һәм әлеге белдерү кәгазен караганда мәнфәгатьләр конфликтын көйләү комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга җыенам/җыенмыйм (кирәклесенең астына сызарга).

| __________ | __________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаны тутырып язу) |